# АКШ ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫ ИР-АТЛАР АРАСЫНДА 4Х100 ДИСТАНЦИЯГӘ КОМПЛЕКСЛЫ ЙӨЗҮ ЭСТАФЕТАСЫНДА АЛТЫН МЕДАЛЬ АЛДЫ

09.08.2015, 19:31

СПОРТ

**Әлеге минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында соңгы ярыш көненең 7 нче финал йөзеше тәмамланды. Ир-атлар арасында 4х100 дистанциягә комплекслы йөзү эстафетасында дөньяның иң әйбәт 8 җыелма командасы ярышты.**

Иң көчле команда булып америкалылар билгеләнде – 3:29.93 секунд күрсәткече белән алар финишка беренче булып килделәр. Икенче күрсәткеч Австралия җыелма командасыныкы булды, аларның вакыты – 3:30.08 секунд. Призерлар өчлеген французлар япты, алар дистанцияне 3:30.50 секунд күрсәткече белән үттеләр.

ДЧ-2015. Йөзү.

Ир-атлар. Эстафета. Комплекс, 4х100.

1. АКШ - 3:29.93

2. Австралия - 3:30.08

3. Франция - 3:30.50

9 август. Казан. "Казан Арена"

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА